Туган телем минем- газиз телем!

Бәхетле мин татар булганга!

Бәхетлемен туган телем белән!

“Рәхмәт” – димен барлык җиһанга!

И. Габдрахманов

Туган тел... Гади генә тоелган әлеге сүзләрнең мәгънәсе тора-тора аңлыйсың. Аңлаган саен туган телеңнең тәмен күбрәк беләсеңдер кебек тоела.

Миңа еш кына республика күләмендә уздырылган укучылар конференцияләрендә катнашырга туры килә. Аларда еш кына татар теленең үткәне, бүгенгесе, киләчәге турындә бәхәсләр алып барыла. Татар теленең дәрәҗәсе кимү , хокуклары кысылу турында фикерләр әйтелә. Яшьтәшләрем, тел галимнәре белән очрашулардан соң, мин үзем өчен гади генә тоелган бер ачыш ясадым. Проблеманы чишү юлларын әллә каян эзлисе юк: ул һәр кешенең үзеннән, гаиләсеннән башланырга тиеш. Туган телгә мәхәббәт, хөрмәт ана сөте белән бергә салына дип уйлыйм.

Телләр белү – изге эш. Белемне - телне күтәреп йөрисе юк. Коръән аятьләрендә Кытайга барып белем ал дигән сүрә бар. Һәр кеше иң элек үз туган телен белергә тиеш. Аллаһы Тәгалә юкка гына “телләр дөньясын” булдырмагандыр дип уйлыйм мин. Димәк, туган телне саклау, аны балаларыңа тапшыру – кешенең иң изге бурычы. Татар һәм рус телләрендә матур итеп сөйләшә белү исә - хәзерге заман таләбе. Моңа исә, бер генә телне дә кимсетмичә, акыл белән ирешергә кирәк. Сүзләремне шагыйрь Зөлфәтнең “Туган тел турында” шигыре белән тәмамлыйсым килә:

Тел ачылгач, үз телеңдә әйтә алсаң: “Әни!” дип,

Тел ачылгач, үз телеңдә әйтә белсәң: “Әти!” дип-

Күзләреңә яшьләр тыгылмас,

Туган телең әле бу булмас.

Соң минутта үз телеңдә әйтә алсаң: “Әни!” дип,

Соң минутта үз телеңдә әйтә алсаң: “Әти!” дип-

Күзләреңә яшьләр тыгылыр-

Туган телең әнә шул булыр!